**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«12» апрель 2019 ел №116

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 сентябрендәге 58 номерлы “Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының 2017 елның 4нче сентябрендәге 64нче номерлы карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасында “бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Г.Гарифуллин**